ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2020 г. Заинск № 474

**“2021 елга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»**

«Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2021 елга расларга:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар кушымтасын;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе вазыйфаларын**
**башкаручы** **М.И. Захарова**

Л.Р. Печина
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 28 октябрь
474 номерлы карары белән
расланган

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешендә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (1 укучыга бер елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | жиде еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |